РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БИК-УТЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИК-ҮТИ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«19» августа 2020 года № 8

Карарга үзгәрешләр кертү турында

«Кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда контрольдә тоту чараларын үткәргәндә үтәлергә тиешле мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте норматив хокукый актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 11 июлендәге 1036 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Бик-Үти авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 17 октябрендәге 10 номерлы «Буа муниципаль районы Бик-Үти авыл җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны кулланучыларда беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә ( алга таба- карар):

1.1. Карарның 1, 3 пунктларын 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адрес буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы
Бик-Үти авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Р.З. Залялетдинов